КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2024 ел, 26 декабрь | г.Казань | № 1216

2025 елга Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы) турында

«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» 2004 елның 26 июлендәге 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2025 елга Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планын (программасын) расларга.
2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 26 декабрь, 1216 нчы
карары белән расланды

2025 елга Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы)

I. 2025 елда Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре

2025 елга Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» 2004 елның 26 июлендәге 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның фараз планнарын (программаларын) эшләү кагыйдәләрен раслау һәм Федераль мөлкәтне хосусыйлаштыру шартлары турында карарлар әзерләү һәм кабул итү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү хакында» 2005 елның 26 декабрендәге 806 номерлы карары белән расланган Дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның фараз планнарын (программаларын) эшләү кагыйдәләре нигезендә, Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерүнең төп бурычларын исәпкә алып эшләнде.

2025 елда Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планын (программасын) гамәлгә ашыруның төп максаты – Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итүнең максималь эффективлыгын һәм аның табышлылыгын тәэмин итү.

Татарстан Республикасының икътисадый үсеше өстенлекләрен исәпкә алып, 2025 елда Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру өлкәсендә дәүләт сәясәтенең төп бурычлары:

житештерүнең инновацияле структураларына инвестицияләр җәлеп итү;

дәүләт мөлкәте составын һәм структурасын оптимальләштерү;

Татарстан Республикасы бюджеты керемнәрен формалаштыру.

Югарыда күрсәтелгән бурычларны хәл итү кысаларында 2025 елда Татарстан Республикасы милкендәге акционерлык җәмгыятьләрнең акцияләрен хосусыйлаштыру һәм дәүләт унитар предприятиеләрен хуҗалык җәмгыятьләренә үзгәртеп кору планлаштырыла.

Әлеге Фараз планына кертелгән, финанс елы тәмамлану вакытына хосусыйлаштырылмаган Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте чираттагы финанс елында хосусыйлаштырылырга тиеш.

2025 елда, бу Фараз планына кертелгән Татарстан Республикасы милкендәге акцияләр пакетлары торгларда сатылган очракта, аларны хосусыйлаштырудан

Татарстан Республикасы бюджетына торглар барышында алынган суммада керемнәр керү көтелә.

II. 2025 елда хосусыйлаштырырга планлаштырыла торган Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте
2025 елда акцияләре хосусыйлаштырырга планлаштырыла торган акционерлык җәмгыятьләре исемлеге

| Акционерлык җәмгыятенең исеме һәм урнашу урыны | «Алтын акция» булу | Устав капиталында Татарстан Республикасы өлеше, процент | Хосусыйлаштырырга планлаштырыла торган акцияләр саны | |
|---|---|---|---|---|
| | | | данә | устав капиталы проценты |
| Склад хуҗалыгы һәм ярдәмче транспорт эшчәнлеге | | | | |
| «Нижнекамскресурсы» акционерлык җәмгыяте, Татарстан Республикасы, Түбән Кама шәһәре | юк | 11,99 | 6 368 | 11,99 |
| «Бөгелмә элеваторы» акционерлык җәмгыяте, Татарстан Республикасы, Бөгелмә шәһәре | юк | 25 процент + 1 акция | 94 473 | 25 процент + 1 акция |
| «Алабуга икмәк кабул итү предприятиесе» ачык акционерлык җәмгыяте, Татарстан Республикасы, Алабуга шәһәре | юк | 7,69 | 2 566 | 7,69 |
| Әзер металл эшләнмәләр (машиналардан һәм җиһазлардан башка) җитештерү | | | | |
| «КАИ-Лазер» сәнәгать лазер технологияләренең төбәк инжиниринг үзәге» акционерлык җәмгыяте, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре | юк | 71,73 | 437 167 892 | 71,73 |
| Сәламәтлек саклау өлкәсендә эшчәнлек | | | | |
| «9 нчы балалар стоматология поликлиникасы» акционерлык җәмгыяте, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре | юк | 45,18 | 37 090 000 | 45,18 |